**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «КРУГЛОЕ ПОЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

11.07.2019 ел № 52/2

**«Авыл җирлегенең аерым сорауларын хәл итү буенча вәкаләтләрне (вәкаләтләр өлешен) тапшыру турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон, Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль милек реестрларын алып бару тәртибен раслау турында» 2011 елныц 30 августындагы 424 санлы приказы, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Круглое Поле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Круглое Поле авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ**:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Советына Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Круглое Поле авыл җирлеге Башкарма комитетының җирле әһәмияттәге мәсьәләнец бер өлешен хәл итү буенча түбәндәге вәкаләтләрен Тукай муниципаль районы Башкарма комитетына тапшыру турында мәсьәләне карарга тәкъдим итәргә:

– авыл җирлегенец муниципаль милегендә булган мөлкәт реестрын алып бару;

– Круглое Поле авыл җирлегенең муниципаль казнасын алып бару.

2. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Советы тарафыннан әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән тәкъдим кабул ителгән очракта, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Круглое Поле авыл җирлеге Башкарма комитетына:

– әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешү төзергә.

3. Әлеге карарны авыл җирлегенең рәсми стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматыныц рәсми порталында урнаштырырга.

5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Круглое Поле авыл җирлеге Башлыгына йөкләргә.

Круглое Поле авыл җирлеге башлыгы,
Совет Рәисе Э.Р. Низамиева